КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 20 июль г.Казань № 869

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында инвестицион климатны яхшырту һәм Россия Федерациясе субъектларындагы Инвестицион климат торышы илкүләм рейтингының иң яхшы тәҗрибәләрен кертү буенча проект офисын төзү турында» 2016 ел, 4 май, 278 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында инвестицион климатны яхшырту һәм Россия Федерациясе субъектларындагы Инвестицион климат торышы илкүләм рейтингының иң яхшы тәҗрибәләрен кертү буенча проект офисын төзү турында» 2016 ел, 4 май, 278 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 27 июль, 511 нче; 2016 ел, 16 декабрь, 936 нчы; 2017 ел, 8 июнь, 363 нче; 2017 ел, 16 август, 584 нче; 2018 ел, 17 гыйнвар, 15 нче; 2018 ел, 25 июнь, 512 нче; 2019 ел, 22 май, 428 нче; 2019 ел, 6 декабрь, 1116 нчы; 2020 ел, 6 апрель, 259 нчы; 2020 ел, 19 декабрь, 1164 нче; 2021 ел, 12 апрель, 241 нче; 2021 ел, 7 сентябрь, 839 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында инвестицион климатны яхшырту һәм Россия Федерациясе субъектларындагы Инвестицион климат торышы илкүләм рейтингының иң яхшы тәҗрибәләрен кертү буенча проект офисы турындагы нигезләмәдә:

3.1 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Проект офисы эшендә катнашу өчен Татарстан Республикасы закон хакимияте органнары, республика башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнары, инвестиция эшчәнлеге субъектлары, иҗтимагый һәм башка оешмалар вәкилләрен җәлеп итәргә;»;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Илкүләм рейтингы күрсәткечләре нигезендә Татарстан Республикасында инвестиция климатын яхшырту буенча «юл картасын» гамәлгә ашыру максатларында республика башкарма хакимият органнары, шулай ук федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнары, инвестиция эшчәнлеге субъектлары, иҗтимагый һәм башка оешмалар өчен методик тәкъдимнамәләр әзерләргә;»;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«үз компетенциясе чикләрендә республика башкарма хакимият органнарыннан, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарыннан, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарыннан, иҗтимагый һәм башка оешмалардан Проект офисы тарафыннан карарлар кабул итүгә кирәкле мәгълүмат соратып алырга;»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында инвестицион климатны яхшырту һәм Россия Федерациясе субъектларындагы Инвестицион климат торышы илкүләм рейтингының иң яхшы тәҗрибәләрен кертү буенча проект офисы (алга таба – проект офисы) составында:

проект офисы составыннан А.А.Кәримовны чыгарырга;

проект офисы составына түбәндәгеләрне кертергә:

Казан шәһәренең «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе генераль директоры Андрей Юрьевич Егоровны (килешү буенча);

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры Олег Владимирович Коробченконы;

«Татэнерго» акционерлык җәмгыяте генераль директорын Рәүзил Мәгъсүмҗан улы Хаҗиевны (килешү буенча);

«Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директорын Рөстәм Фәннур улы Хамматовны (килешү буенча);

Яков Вениаминович Геллерның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт заказы агентлыгы» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча)»;

Радик Вахитович Рамазановның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Транспорт өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Идел буе федераль округы буенча төбәкара территориаль идарәсе башлыгы урынбасары (килешү буенча)»;

Илшат Шәех улы Фәрдиевның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин